МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.12.2023 Казан ш. № 02-145

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 19.11.2021ел, № 02-115 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 19.11.2021ел, № 02-115 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә (11.07.2022 ел, № 02-88, 02.11.2022 ел, № 02-132, 09.12.2022 ел, № 02-145, 29.12.2022 ел, № 02-153, 27.03.2023 ел, № 02-23, 27.10.2023 ел, № 02-116, 20.12.2023 № 02-140 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
« 25 » 12.2023 ел,
№ 02-145
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 19.11.2021ел, № 02-115 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турында күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1 «Тиешле максатчан статьялар исемлеге һәм аларны Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чыгымнарына кертү кагыйдәләре» 2 пунктының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында «14 6 06 00000 Агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарны компенсацияләү» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- R474F Шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны гамәлгә кертү өчен маркировка җиһазларын сатып алуга һәм сәнәгатьтә файдалануга тапшыруга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны гамәлгә кертү өчен маркировка җиһазларын сатып алуга һәм сәнәгатьтә файдалануга тапшыруга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Башка бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.».

2. 2нче кушымтада түбәндәге юлдан соң

| | |
|---|---|
| «14 6 06 R472F | Шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «14 6 06 R474F | Шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды средстволары хисабына, агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны гамәлгә кертү өчен маркировка җиһазларын сатып алуга һәм сәнәгатьтә файдалануга тапшыруга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга финанслашыла торган чыгымнар». |